Удмурт дәүләт университеты
Чит телләр һәм әдәбият институты
“Күптеллелек һәм мәдәниятара багланышлар” Халыкара лабораториясе

# “Воткинскидан Вундеркинд: Чайковский”

**дип исемләнгән Халыкара проект**

**Композиторның тууына 175 ел тулу уңаеннан**

(Ил байраклары)



*Рус-Ананы миннән дә көчлерәк яраткан*
*кешене мин әле очратмадым. Мин рус кешесен,*
*рус йөзенең күркәмлеген, сөйләмен,*
*рус халкының фикер сөрешен*
*рус гореф-гадәтләрен көчле бер дәрт*
*белән яратам* (И.П. Чайковский, 1886 елгы көндәлек)

1837 елда булачак композиторның әтисе Илья Петрович Чайковский Кама-Воткинск заводына җитәкче итеп билгеләнә һәм тормыш иптәше белән шунда төпләнә. 1840 елның 25 апрелендә аларның улы Петр дөньяга килә. Зур завод җитәкчесенең тормыш уңайлыкларын булдыру өчен бөтен мөмкинлекләре була: матур иркен өе, хезмәтчеләре, балалар өчен тәрбиячеләр, хәтта үзенең 100 казактан торган гаскәр сыман сугышчылары. Өй бик кунакчыл була. Әтисенең ачык йөзле, ягымлы булуы, хатынының күркәмлеге Чайковскийларның йортын Воткинск җәмгатьчелегенең иң яраткан урынына әверелдерә. Бу җәмгыятьтә һич тә провинциаль шәһәр чалымнары сизелми, ә киресенчә, Санкт-Петербургтан хезмәт итәргә килгән яшьләрнең бик күп булуы, Карра исемле инглиз кешесенең гаиләсе кебек үтә дә гыйлемле гаиләләр булуы Россия үзәгеннән ераклыкны онытырга мәҗбүр итә.

Гаилә үсә бара, беренче балалары – Зинаида, Николай, Петрдан соң бер-бер артлы Александра һәм Ипполит дөньяга килә.

Әнисе Александра Андреевна, балаларга өйдә тәрбия һәм башлангыч белем бирү өчен, Петербургтан француз гувернанткасын Фанни Дюрбахны алып кайтканда, Петрга дүрт яшь ярым гына була. Ләкин әнисе, белем алырга теләп күз яше белән ялваруын күреп, Петяны укырга бирә. Шул көннән башлап бертуган апа-абыйсы белән бергә шөгыльләнеп, кыска гына вакыт эчендә бөтен фәннәр буенча аларны куып та җитә. Эш көннәрендә иртәнге алтыдан башлап вакыт катгый бүленгән була һәм көн тәртибе төгәл, җиренә җиткереп үтәлә. Үз эшләре белән шөгыльләнер өчен балаларның вакыты чикләнгән була.

Петя алты яшендә инде ирекле рәвештә русча, французча һәм алманча укый. Фанни әйтүенчә, беренче очрашудан ук ул иң кечкенә укучысын аеруча якын күрә, һәм бу дәресләр вакытында өлкәнрәк балалардан сәләтлерәк һәм тырышрак булуы өчен генә түгел, ә һәр башкарган эшендә аның белән очрашкан һәркемне сокландыра торган, сүз белән аңлата алмаслык нидер сизелгәнлектән була. Класста аннан да тырышрак һәм зиһенлерәк булу мөмкин булмаган, ял иткәндә беркем дә күңеллерәк уен уйлап таба алмаган, фикер алышканда, аннан да кызыклырак һәм үзенчәлекле фикер әйтүче булмый. Өлкәннәрне аның бик хисчән булуы гаҗәпләндерә, юк кына сәбәп тә аны рәнҗетә алган. Элекке гувернантка сүзләре буенча, бу бала бик йомшак күңелле була.

Китаплар уку, Воткинск әйләнә-тирәсендә йөрү, рус булган һәрнәрсәгә карата күңелне эретә торган, искиткеч бәйләнешнең башлангычы була һәм гомере буена юлдашына әверелә. Фанни Дюрбах истәлекләре буенча, ул башка балалар белән йорт балконыннан тирә-якта яңгыраган ягымлы һәм моңсу җырларны игътибар белән тыңлаган. Халык җыры, Воткинскидан башлап, композиторның иҗади тормышының аерылгысыз юлдашы була. «Сабыйлык чорыннан ук мин рус халык музыкасының үзенчәлекле билгеләренең аңлатып бетергесез матурлыгы белән сугарылдым, мин рус элементының бар чагылышларын шашып яратам», – дип язган П.И. Чайковский.

Биш-алты яшендә ул француз телендә шигырьләр яза башлый. Менә бу җиде яшьлек малайның беренче шигырьләренең берсе (без орфографиядәге кайбер төгәлсезлекләрне, төшеп калган тыныш билгеләрен куймыча китерәбез):

I’UNIVERS

Éternel notre Dieu c’est toi qui a fait tout cela
Enfant! regarde ces plantes si belles
Ces roses, ces germandrées, elles sont si belles.
Brillan soleil éclaire tou le monde
C’est cette Ettre qui la fai
La lune étoiles eclaire notre nui
Sans toi le blé n’oré put etre
Les vag(u)es de ces belles aux
Nous expirerons sans eux

Les mers dont i’etendu est si grande
Les fleuves I’entoure
Mère! Nourissé! Nourissé Vos enfants
Le bon Dieu les a crée
Dieu
Puissant on t’adore.

ВСЕЛЕННАЯ

Вечный наш Бог! ты сделал все это.
Дитя! смотри на эти растения столь красивые
Эти розы, эти вероники, они так красивы
Блестящее солнце освещает весь мир
Это существо создало его
Луна звезды освещают нашу ночь
Без тебя хлеб не мог бы расти
Волны этих красивых вод
Мы бы умерли без них

Моря которых притяжение так велико
Речки их окружают
Мать, питайте! питайте ваших детей
Бог создал их
Боже могучий тебе поклоняются

07 октября 1847 г.

Малайның Ватанга мәхәббәте аның һәр шигырендә чагылыш таба, мәсәлән:

SUR MA PATRIE

Oh! patrie que j'aime
Je ne veux point te quitter
J'existe ici, j'i mourrai aussi
Oh! Patrie, que j'aime
Ma terre chérie.
Oh je n'irai point la
Chez un peuple etranger
Je t'honnore ma patrie
Je n'honnore point une autre
Ma ville natale est petite
Et trés peut peupler
Mais je l'honnore toujours
Et je l'honnorerai.
Si je vivrai dans un peuple étranger
Oh! je serais bien triste
Mais mon bon Dieu
Fais que je n'irai pas.
Je…………
Et ne veux pas
Ma Russie trés chérie
Je…………

К МОЕЙ ОТЧИЗНЕ

О! отчизна, которую я люблю
Я не хочу тебя покинуть
Я существую здесь, здесь и умру
О! отчизна, которую я люблю
Моя дорогая земля.
О я не пойду туда
К чужеземному народу
Я тебя чту моя отчизна
Я не чту совсем другой
Мой родной город маленький
И очень мало населенный
Но я все-таки чту всегда
И буду чтить
Если я буду жить у чужеземного народа
О! я буду очень печален
Но боже мой
Сделай чтобы я не ушел
Я….
И не хочу
Моя Россия дорогая
Я…

*1848 г.*

Французча язылган бу шигырьләре белән танышкач, аны гаиләдә «Le petit Pouchkine» (“Кечкенә Пушкин”) дип йөртә башлыйлар.

Малай чакта Чайковскийны Жанна д'Аркның батырлыгы гаҗәпләндерә һәм үзенә җәлеп итә. Гади көтүче кызның Туган илен яклауда тиңсез батырлыгы аны сокландыра. Жанна д'Арк аның яраткан герое булып кала, соңрак язылган “Орлеанская дева” (“Орлеан кызы”) операсының иҗат ителүенә да бу батырлык илһам, дәрт биргән.

Петрның музыкага сәләте балалык елларында ачыла һәм үсеш ала. Гаиләдә барысы да музыка белән кызыксынган, әнисе матур җырлый, балаларга бию көйләре уйный. Булачак композиторның беренче уен коралы оркестрина – уртача зурлыктагы яңгыравыклы механик орган була. Әтисе аны Воткинскийга Петербургтан алып кайта. Соңрак Петр Ильич оркестрина кылларының тирбәлеше аның күңелендә көчле музыкаль тойгылар уятуын искә ала. Ул көннәр буе аның тавышын тыңлап утыра алган, уен коралының сихри аһәңе аның тәэсирләндергән, күңеленә үтеп кергән. Әнисенең Моцарт әсәрләрен башкаруы, аны бигрәк тә таң калдырган. «Дон Жуан»нан өзекләр тыңлау бу талант иясенә карата көчле соклану хисләре уяткан. Россини, Беллини, Доницетти әсәрләре белән дә ул шушы уен коралы аша танышкан һәм гомере буена шул музыкага тугъры булып калган.

Музыканы кабул итү сәләте малайда кечкенәдән ачылган. Ул биш яшендә оркестрина аша ишеткән көйләрен фортепианода уйный башлаган. Фортепианода уйнауны тыйгач, ул төрле предметларда уен коралында уйнагандай хәрәкәтләр ясый торган булган. Бервакыт шул дәрәҗәдә бирелеп,

тәрәзә пыяласында бармаклары белән йөрткән, хәтта тәрәзә ватылып, аның кулы киселгән. Шул вакыйгадан соң, аның әти-әнисе баланың музыка белән кызыксынуына җитди карый башлаганннар. Музыка укытучысы Марья Марковна Логинованы чакырганнар. Кечкенә Петр беренче музыкаль белемен шул гади кыюсыз кыздан алган. Воткинскига Шопен мазуркаларын уйнарга ярата торган офицер Машевскийның килүе кечкенә Петр өчен чын-чынлап бәйрәм була. Аның бер килүенә, Петр Шопенның ике мазуркасын әзерли. Ул бу көйләрне шулкадәрле яхшы башкара, хәтта Машевский шатлыгыннан аны кочаклап үбә.

1848 елда Чайковскийлар гаиләсе Петербургка күчеп китә. Петербургта аларның туганнары, танышлары да күп була. Гомерендә беренче тапкыр күргән театр да, яңа танышлары да, яңа тәэсирләр дә малайда Воткинский хатирәләрен оныттыра алмый. Барлык балалар да Воткинскийдагы бәхетле тормышны сагынып искә алалар. Йомшак күңелле Петр өчен Воткинскийдагы сигез ел гомернең чын җылы гаилә учагында үтүен Петрның энесе дә үзенең китабында язып чыга.

Күпчелек балаларны мондый хәл иркәли, боза һәм эшлекле тормышка сәләтсез итә, әмма кечкенә Петяга, күңеленең иң яхшы сыйфатлары үсеше өчен тулы иркенлек биреп, ул форсат уңайлы була. Әти-әнисеннән мирас итеп алынган якыннарны яратуы һәм аларга миһербанлы булуы аны үз-үзеңне яратудан, сабырсызлыктан, шәфкатьсезлектән корыч тышча кебек саклап киләләр.

Табигый акыл һәм күзәтүчәнлек аңа үзенә күрә бер мул тормышын аңларга һәм бәяләргә мөмкинлек бирделәр, әмма шуның белән бергә тере җаннарның җәфаларын да сиздерделәр. Барысы да аның, суга батырырга теләгән песи хакында борчылганын; аларның өенә дәрес бирергә килгән мескен ятим Веничканы кызгануы; соңга таба мохтаҗлыкта яшәгән карт музыка укытучысы Логинованы кайгыртуы һәм элеккеге гувернанткасы Фанни Дюрбахка барып йөрүләре турында искә алалар. Әти-әниләрен һәм якыннарын ул яратып кына калмаган, ә аларның кадерләрен белгән. Шуның белән рәхмәтлелек, яхшылыкка яхшылык белән җавап бирергә әзер тору аңлатыла, андагы тырышлык һәм юашлык тирә-яктагыларны сихерли. Ул якын-тирәдәге барлык кеше дә аңа бары тик яхшылык кына теләвен белә, һәм чын күңелдән шулай ук җавап та бирә. Аның ышанучанлыгы, намуслылыгы, дөреслеккә омтылуы да нәкъ менә шуннан. Шулай ук көнчелекнең булмавы һәм үзенең сәләтенә карата тыюлы караш та шул ук мөнәсәбәт нәтиҗәсе.

Еллар, ун еллар уза, әмма Чайковскийның көе элеккечә кешенең балачагына кушылып “Балачак альбомы” битләренә, “Кечкенә Лизочка” турындагы җырларга үрелә.

Буын артыннан буын аның “Ел фасыллары” һәм кардәш рус тургайларның язгы сайраулары, кечкенә кыңгыраулы рус тройкаларының карлы тигезлекләрдә яңгыравы турында белә.

Элеккечә, Пушкин белән берлектә Чайковский дулкынландыргыч “Онегин” һәм “Карга ханбикә” (“Пиковая дама”) көйләре белән безнең яшьлеккә гомерлеккә килеп керә. Ә без зурайган саен, аның мәңге үлмәс

симфонияләре аша кеше тормышы һәм хисләре, уйланулар тагын да киңрәк һәм тирәнрәк ачыла.

Шулай гомер буе безне аның таныш, мәңге онытылмас көйләре озатып бара, алар я соклandыргыч уйчан, я ялкынлы шатландыргыч, шомлы һәм кыю, кәефсез һәм якты, әмма һәрвакыт эчкерсез һәм туры сүзле, алар аша үзебезнең шатлык-кайгыларыбызны, хәтер һәм өметләрне, безнең уйларыбызны, мәхәббәтебезне ишетәбез.

Үз гасырының танылган музыканты, бүгенге көндә аеруча ,рус көе һәм сәнгатенең символик фигурасы булып тора. Ул тагын нәрсә эзләгән һәм теләгән соң, аңа якынлашып килгән “киләчәктә” нәрсә күренгән.  Һәм кабат тыныч, уйчан җавап ишетелгәндәй була: “Мин бар күңелем белән көемнең таралуын, аны яратучы, анда юаныч һәм ышаныч таба алучы кешеләр саны артуын  теләр идем...”

Координатор  проекта Е.Б. Бубекова, ЕИ КФУ